ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
25.02.2020

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
№ 325

Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 нче статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия төзергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 нче елның 25нче февралендәге
325нче номерлы карарына карата
1нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге Муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия составы

1. Сибгатуллин Хәйдар Хабибулла улы –Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы(килешү буенча), комиссия рәисе;
2. Садриева Люция Рахимулла кызы – 5 нче сайлау округы буенча Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы депутаты, комиссия секретаре;
3. Гыймадиев Марат Ярхаметдин улы – 2 нче сайлау округы буенча Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы депутаты;
4. Сафиуллина Гөлнара Хамис кызы – 4 нче сайлау округы буенча Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы депутаты;
5. Фаязов Фирдүс Тәүфикъ улы – 7 нче сайлау округы буенча Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы депутаты;

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 нче елның 25нче февралендәге
325нче номерлы карарына карата
2нче кушымта

# Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия турында нигезләмә

## 1.ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасының нәтиҗәле эшләвен булдыру, эзлекле камилләштерү һәм тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли торган булып тора һәм үз эшчәнлеген билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашыра.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынучы юридик һәм физик затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.

## 2.КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.
2.2. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:
3.1.1. Җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасын эзлекле рәвештә формалаштыру һәм камилләштерү

процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләү, ә алга таба аларны тормышка ашыру;
3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләүгә бәйле рәвештә гражданнар һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;
3.1.3. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү:
- Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;
- Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы мәсьәләләр буенча;
- Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне кире кагуга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча;
- Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектлары буенча;
- Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен ызанлау проектлары буенча.
3.1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү керә.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк саен җыела, ләкин аена бер тапкырдан да ким түгел.
4.2. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.
4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.
4.4. Комиссия эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.